**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ТАТАРСКО-САРАЛОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
422633,РТ, Лаишевский район, село
Татарские Сaралы, ул.Татарстан, д.17
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАТАР САРАЛАНЫ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422633, РТ, Лаеш районы, Татар Сараланы
авылы, Татарстан урамы, 17 нче йорт
тел: 8-(84378) -4-77-49
факс: 8-(84378) -4-77-49

**2024 елның 14 ноябре** **182 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 16 апрелендәге 91 номерлы Татар Сараланы авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ««Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 маендагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Сараланы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 16 апрелендәге91 номерлы Татар Сараланы авыл җирлеге Советы карарына (10.05.2018 № 95, 18.10.2018 № 113, 21.09.2020г № 5, 31.10.2022г № 105, 09.11.2022г № 107, 24.01.2023г №, 24.06.2024г №165 Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге Советы карарларына кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктта "13 323" саннарын "13 990" саннары белән алыштырырга;

күрсәтелгән карарның 2 нче кушымтасын яңа редакциядә (кушымта)бәян итәргә.

1. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә туны муниципаль районның Татар Сараланы авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисади үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы Исхаков Н.Н.**

Татарстан Республикасы муниципаль районының
Татар Сараланы авыл җирлеге Советының 2018 елның
16 апрелендәге 91номерлы карарына 1нче кушымта
(ТатарстанРеспубликасы муниципаль районының
2024 елның 14 ноябрендәге 182 номерлы Татар Сараланы
авыл җирлеге Советы карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлык коэффициентлары

| Вазыйфаның исеме | Тугызынчы төркем <*> | Унынчы төркем <*> | Унберенче төркем <*> | Уникенче төркем <*> |
|---|---|---|---|---|
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 26 029 | 22 810 | 20 991 | 19 173 |

<*> Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы чыгымнарын формалаштыру нормативларының 1 пункты нигезендә муниципаль берәмлек кергән хезмәт өчен түләү төркеме.

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Сараланы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакы күләмен билгеләү максатыннан тиешле муниципаль берәмлек статусына һәм аның территориясендә даими яшәүче халык санына карап түбәндәге хезмәт хакы төркемнәре буенча бүленә:

1) шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә барлыкка килгән авыл һәм шәһәр торак пунктлары:
тугызынчы төркем 10 меңнән артык кеше яшәгән муниципаль берәмлекләр;
унынчы төркем - халык саны 5 меңнән 10 меңгә кадәр булган муниципаль берәмлекләр;
унберенче төркем - 1,5 меңнән 5 меңгә кадәр кеше яшәгән муниципаль берәмлекләр;
уникенче - төркем халык саны 1,5 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләр.
.